**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
23.03.2020

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-57

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 10 февралендәге ПР-18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (балалар бакчалары)

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 8 апрелендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 293 номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турында» 30.05.2019 ел № ТС - 1334/13 хаты нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1.Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.02.2020 № ПР-18 карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының 12 абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 13,14,15 абзацларны тиешенчә 12,13,14 абзацлары дип санарга;

1.3. 1.2 пунктның 11 пунктчасында "наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 3.3.6 пунктының икенче абзацында «Агымдагы елның 1 сентябренә комплектланган вакытта системада балаларның яше» тәкъдимен төшереп калдырырга;

3.3.6 пунктының 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Белем бирү оешмасына буш урыннар булганда, барлык календарь ел дәвамында кабул ителә»;

2.8 пунктының 2 графасында «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» II бүлегенең таблицалары «- теләгән оешмада тәрбия һәм укытуның теләгән телнең туры килмәве» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев